Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы 18 нче катнаш балалар бакчасы
муниципаль мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү бюджет учреждениясе

# Баскычтан менәм

## 4-6 яшьлек рус балалары өчен дидактик уен




Гыйльметдинова Миләүшә Рәшит кызы,
югары квалификацион
категорияле
татар теле тәрбиячесе

**Максат:** Татар теленә кызыксыну уяту. Аралашу теләге тудыру. 1-5 кә кадәр санау тәртибен ныгыту.

## 1 ысул “Бир әле”

**Максат:** Бер-береңнән сорап алуны , санау тәртибен ныгыту. “Ничә?” соравына дөрес, аңлап җавап бирүләренә ирешү

**Уен барышы:**

Бала тәрбиячедән үзенә охшаган уенчыкны сорап ала (аю, песи, куян...).
**-Миңа аю бир әле.**
**-Мә, аю. Аю матур. Аю зур.**
**-Рәхмәт!**
Сайлаган уенчык белән санап баскычтан менә. Тәрбияче “Ничә?” соравы аша уенчыкның ничәнче баскычта икәнен ачыклый.




Уен – кызыксыну һәм белемгә омтылу утын кабыза торган очкын ул.
В.А.Сухомлинский.

## 2 ысул “Баскычтан менәм”

**Максат:** Шигырь сүзләрен хәрәкәтләр белән тәңгәл китерүне, санау тәртибен ныгыту.

**Уен барышы:**

Бала үзе сайлап алган уенчык белән **“Бер, ике, өч, дүрт, биш аю,**
**Зур аю, матур аю.”**
җырын җырлап баскычтан менә.




Уен – ул бала эшчәнлегенең, тормышының аерылгысыз өлеше

# 3 ысул “Ничә?”

**Максат:** “Ничә?” соравына дөрес, аңлап җавап бирүләренә ирешү, саннарны ныгыту.

**Уен барышы:**

Бала үзе сайлаган уенчыкны бер баскычка куя. “Ничә?” соравы аша иптәшеннән ничә уенчык икәнен сорый.

**-Ничә?**
**-Бер куян.**







